| Республика Татарстан<br>Глава Тураевского сельского поселения<br>Менделеевского муниципального района<br>423647, Менделеевский район, с. Тураево,<br>ул.Центральная, д 11а | Татарстан Республикасы<br>Менделеевск муниципаль районы<br>Турай авыл җирлеге Башлыгы<br>423647, Менделеевск районы, Турай авылы,<br>Үзәк урамы, 11а |
|---|---|

тел./факс 8/85549/2-73-31, E-mail: Tur.Men@tatar.ru, http://mendeleevsk.tatarstan.ru/rus/turaevskoe-selskoe-poselenie.htm


ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

8 ноябрь 2019 ел. № 2

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлегенең
Татар Әхтиялы авылында
гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын үткәрү турында

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Турай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә **КАРАР БИРӘМ:**

1. 2019 елның 24 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Татар Әхтиялы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә. Җыенны уздыру урыны итеп татар Әхтиялы авылы мәдәният йортын билгеләргә: Татар Әхтиялы авылы, Үзәк урамы, 9 Б йорт.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2020 елда Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлегенең Татар Әхтиялы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- зират коймасын ремонтлау һәм материаллар сатып алу.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Турай авыл җирлеге» бүлегендә кабул ителгән көннән алып 3 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Турай авыл җирлеге башлыгы Рахимова А.М.